ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «29» февраленнән № 77

**«Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр күләмнәре турында» 2015 елның 23 сентябрендәге 698 номерлы карары нигезендә, Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, балаларны балансклы кайнар ризык белән тәэмин итү максатларында карар бирәм:

1. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1. Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүне һәр уку көненә 6 сум 50 тиен күләмендә субсидия һәм ата-аналар түләвеннән торган суммага оештырырга.

1.2. Аз керемле гаиләләрдә укучылар өчен җирле бюджет чаралары исәбеннән бәясе 25,62 тиен булган, шул исәптән 6 сум 50 тиен субсидия, иртәнге кайнар аш белән тәэмин итүне оештырырга (1 нче кушымта)

1.3. Туклануны оештыруны контрольдә тотырга

1.4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының аз керемле гаиләләрендә укучыларны бушлай тукландыруны тәэмин итү тәртибе турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

1.5. Укучыларның туклануын оештыруны тикшереп тору буенча район ведомствоара комиссия составын расларга (2 нче кушымта).

2. Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды исәбеннән 121133,88 сум күләмендә аз тәэмин ителгән гаиләләрдән булган балаларга түләүсез туклану оештыру чыгымнарын финансларга.

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә (А.Л.Еронтьевка):

.

3.1. Витаминнар, микронутриентлар белән баетылган төп туклыклы матдәләрне карап тоту буенча балансланган иртәнге һәм төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

3.2. Укучыларның кайнар туклануын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны максатчан куллануны һәм исәпкә алуны тикшереп торуны тәэмин итәргә.

3.3. Мәктәп яны участоклары продукциясе хисабына мәктәп ашлары ассортиментын баету буенча эшне көчәйтергә.

3.4. Гомуми белем бирү оешмаларына продуктларның өзлексез китерелүен координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

4. Мәктәп укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүче гомуми белем бирү учреждениеләре һәм башка предприятиеләр җитәкчеләренә:

4.1. Мәктәп ашханәләрен сыйфатлы азык-төлек белән өзлексез тәэмин итәргә.

4.2. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруны, санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм «гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар туклануын оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре» СанПин 2.4.5409-08 нормативлары нигезендә, «Санитар кагыйдәләрне үтәү һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактика) чаралар үтәүгә производство контролен оештыру һәм үткәрү» СП 1.1.1058-01 номерлы СанПиН нигезендә производство контролен башкарырга.

5. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының аз керемле гаиләләрендә укучыларны түләүсез тукландыруны тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015елның 23 ноябрендәге 327 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1631003397
ОГРН 1051660041740

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башкарма
комитетының
2016 елның «29» февраленнән
77 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Бушлай туклануга дәгъва кылучы балалар**

| Баланың ФИО | Мәктәп |
|---|---|
| 1. Гатина Энҗе<br>2. Гатина Фирүзә<br>3. Гатин Фирзәр | Тубылгытау төп гомуми белем мәктәбе<br>5768,28 |
| 4. Лоос Дмитрий<br>5. Астфьев Николай | МББУ Архангельск төп гомуми белем мәктәбе<br>3845,52 |
| 6. Җиһаншин Павел<br>7. Җиһаншина Маргарита<br>8. Спиридонова Александра<br>9. Флягина Елена<br>10.Смирнов Кирилл<br>11.Драчева Мария<br>12.Сипатров Владимир<br>13.Еграшкин Вадим<br>14.Петровичева Юлия<br>15.Левина Любовь<br>16.Малышева Аида<br>17.Лодыгина Виктория<br>18.Лодыгин Никита<br>19.Карташова Виктория<br>20.Гыйльманов Рәсил<br>21.Петров Павел<br>22.Кошкин Андрей | Новошешминская башлангыч мәктәбе<br>32686,92 |
| 23.Сушков Никита<br>24.Каранаева Ангелина<br>25.Писцов Николай<br>26.Саранова Камиллла | Петропавловка төп гомуми белем мәктәбе<br>7691,04 |

| | |
|---|---|
| 27.Булатова Алена<br>28.Булатова Светлана<br>29.Булатова Анастасия<br>30.Миронов Влас<br>31.Миронов Олег<br>32.Әглиуллина Аделина<br>33.Әглиуллина Диана<br>34.Францева Евгения<br>35.Францев Роман<br>36.Ларионов Владимир<br>37.Кудряшов Валентин<br>38.Кудряшов Павел | Яңа Чишмә урта гомуми белем мәктәбе<br>23073,12 |
| 39.Пронин Никита<br>40.Пронина Анна<br>41.Арсеньева Ирина<br>42.Арсеньев Иван | Кызыл Октябрь төп гомуми белем мәктәбе<br>7691,04 |
| 43.Глушков Максим<br>44.Глушков Милан | Волчья Бистәсе төп гомуми белем мәктәбе - 3845,52 |
| 45.Исмаилов Шамил<br>46.Пузиков Данил<br>47.Смирнова Ирина<br>48.Пузикова Настя<br>49.Писоцкий Максим<br>50.Панков Данил<br>51.Поляков Максим<br>52.Малышева Настя<br>53.Җиһаншина Маша<br>54.Левина Оля<br>55.Карцев Алексей<br>56.Пузиков Максим<br>57.Җигһаншина Настя<br>58.Курбатов Алексей<br>59.Охотникова Виктория | Яңа Чишмә гимназиясе -<br>28841,40 |
| 60.Ситдиков Рамазан<br>61.Игошин Радмир | Чертуш башлангыч мәктәбе<br>-<br>3845,52 |
| 62.Бахтимиров Роман | Әдәмсә төп гомуми белем мәктәбе -<br>1922,76 |
| 63.Охотникова Вера | Чуаш Чабаксары төп гомуми белем мәктәбе<br>1922,76 |

Раслыйм
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма җитәкчесе
________________Р.Р. Фасахов

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЗ КЕРЕМЛЕ ГАИЛӘЛӘРЕННӘН КИЛГӘН УКУЧЫЛАРНЫ ТҮЛӘҮСЕЗ ТУКЛАНДЫРУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Төп нигезләмәләр

Нигезләмә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру, социаль ярдәм һәм балаларның сәламәтлеген ныгыту, белем бирү процессының уңайлы мохитен булдыру максатларында эшләнгән.
1. Әлеге Нигезләмә түбәндәге документлар нигезендә эшләнгән:
. - «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы
«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон;
- «СанПиН 2.4.5. 2409-08 раслау турында» 2008 елның 23 июлендәге 45 нче карары (28.08.2008).
1.2. Әлеге Нигезләмәнең тәэсире барлык укучыларга да тарала.
1.3. Нигезләмә билгесез вакытка кабул ителә.
1.4. Әлеге Нигезләмә аз керемле гаиләләрдән килгән укучыларны бушлай тукландыруны оештыру тәртибен билгели.
1.5. Гаиләнең бер әгъзасына җан башына уртача керем Татарстан Республикасы буенча билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган аз керемле гаиләләрдә укучылар түләүсез туклану алуга дәгъва кыла.
1.6. Түләүсез туклану алу өчен балигъ булмаганнарның ата-аналары «ТР Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль бюджет учреждениесенә туклануны оештыруны тикшереп тору буенча ведомствоара комиссия рәисе исеменә тапшырырга тиеш:
- гариза;
- яшәү урыны турында белешмә;
- гаиләнең барлык әгъзаларының керемнәре турында: соңгы 3 айдагы хезмәт хакы, вакытлыча эшкә сәләтсезлек буенча пособиеләр, стипендияләр, эшсезлек буенча пособиеләр, алиментлар турында белешмәләр. Аннан соң комиссия балалар исемлеген туклануны оештыруны контрольдә тоту буенча район комиссиясенә бирә.
1.7. Социаль ташламалар һәм түләүләр (балаларга айлык пособиеләр, торак субсидияләре, барлык төр социаль пособиеләр) алу турында мәгълүматлар мәгариф бүлегенә халыкны социаль яклау органнары соравы буенча бирелә.
1.8. Аз керемле гаиләләрдәге балаларга түләүсез туклану мәктәп укучыларының туклануын оештыруны тикшереп тору буенча ведомствоара комиссия карарлары нигезендә бирелә.
1.9. Бушлай ашау кайнар иртәнге аш (төшке аш) рәвешендә генә бирелә.

## 2. Мәктәптә бушлай туклануны оештыру механизмы

2.1. Укучыларның туклануын оештыруны контрольдә тоту буенча комиссия төзү һәм

комиссия әгъзалары арасыннан түләүсез туклануны оештыру өчен җаваплы кеше билгеләү. (1 нче кушымта.)
2.2. Мәгариф учреждениеләре түләүсез туклануга мохтаҗларны ачыклый һәм бушлай туклану өчен документлар пакетын формалаштыруда, аларны район ведомствоара комиссиясенә тапшыруда ярдәм итә.
2.3. Мәгариф учреждениеләре һәр пакетка аз керемле гаиләләрне матди-көнкүреш тикшерүе актын төзи, ул мәктәп директоры тарафыннан раслана һәм мәктәп мөһере белән раслана. Берничә гаиләнең бер торак мәйданында бергә яшәгәндә хуҗалыкны аерым алып бару факты әлеге акт белән раслана.
2.4. Барлык документ пакетларын тикшерү һәм раслау өчен ведомствоара комиссиягә тапшыру.
2.5. Ведомствоара комиссия карарлары нигезендә аз керемле гаиләләрдән укучыларга түләүсез туклану исемлеген раслау.
2.6. Югарыда күрсәтелгән категориядәге балаларны тукландыруның муниципаль контракты нигезендә бүлеп бирелгән ассигнованиеләр чикләрендә түләү.
2.7. Ашханәдә аз керемле гаиләләрдән укучыларны тукландыруны оештыру расланган исемлекләр нигезендә бары тик кайнар иртәнге аш (төшке аш) рәвешендә генә.
2.8. Көн саен һәм ай саен ОШСП буенча МУП белән фактик туклану турында чагыштыру актын төзү. Актны район буенча җыелма актлар төзү өчен «ТР Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә тапшыру.

## 3. Мәктәптә туклануны оештыруны контрольдә тоту

3.1. Мәктәпләрдә укучыларның туклануын оештыруны агымдагы контрольдә тотуны туклануны оештыру өчен җаваплы мәктәпнең медицина персоналы, туклануны оештыруны контрольдә тоту өчен махсус төзелгән мәктәп комиссиясе һәм туклануны оештыруны контрольдә тоту комиссиясе башкара.
3.2. Мәктәптә туклануны оештыруны контрольдә тоту комиссиясе составы һәр елның 1 сентябрендә мәктәп директоры боерыгы белән раслана, ә комиссия составы ТР Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башкарма
комитетының
2016 елның «29» февраленнән
77 номерлы карарына
2 нче кушымта

УКУЧЫЛАРНЫҢ ТУКЛАНУЫН ОЕШТЫРУНЫ ТИКШЕРЕП ТОРУ БУЕНЧА РАЙОН ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯ СОСТАВЫ

Фасахов Р. Р, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе - комиссия рәисе;
Семеняк В.Н., Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары - комиссия рәисе урынбасары;
Еронтьев А.Л., «ТР Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ башлыгы - комиссия секретаре;

Комиссия әгъзалары:
Гайфетдинова А. Х., ТР Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының халыкны социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча)
Иванова Н.А., ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чишмә МРда «Забота» үзәге директоры (килешү буенча)
Янова Е.П., «ТР Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ балаларының тәрбия эше һәм өстәмә белем бирү буенча методисты (килешү буенча)
Ю. Е. Кузнецова, «ТР Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ үзәкләштерелгән бухгалтериясенең баш белгече (килешү буенча)